СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 декабрь, 2024 ел** **№ 482**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2014 елның 31 мартындагы 340 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 15 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, торак пунктлар чикләрен билгеләү максатында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 21 октябрендәге 10-53/13466 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 340 номерлы карары (Советның 28.12.2016 № 117, 28.12.2020 № 50, 29.09.2023 № 322 карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Биектау муниципаль районы рәсми сайтында (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru) игълан итәргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамөтдинов